## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Кече Әтнә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

"13" ноябрь 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №126 карары нигезендә, 2021 елның 13 октябрендә «Сез 2022 елда Олы Әтнә авыл җирлеге Кече Әтнә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Кече Әтнә торак пунктында территорияне төзекләндерү һәм чистарту(үлән чабу агач һәм куакларны кисү, үсентеләрне чистарту, бура материалларын һәм чүп-чарны каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр илтү);
2) Зиратны карап тоту һәм төзекләндерү (инвентарь йортын ремонтлау);
3) Спорт мәйданчыгы төзү;
4) Янгын гидрантларының якындагы зонасын таләпләргә туры китерү (үлән чабу,грунтны тигезләү, табличкалар урнаштыру

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

**Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:**

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 195 (йөз туксан биш) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 136 (йөз утыз алты) кеше, 69,7%.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы136 (йөз утыз тугыз алты) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (ноль) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Кече Әтнә авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

"Сез 2022 елда Олы Әтнәавыл җирлеге Кече Әтнә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Кече Әтнә торак пунктында территорияне төзекләндерү һәм чистарту(үлән чабу агач һәм куакларны кисү, үсентеләрне чистарту, бура материалларын һәм чүп-чарны каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр илтү);

2) Зиратны карап тоту һәм төзекләндерү (инвентарь йортын ремонтлау);

3) Спорт мәйданчыгы төзү;

4) Янгын гидрантларының якындагы зонасын таләпләргә туры китерү (үлән чабу,грунтны тигезләү, табличкалар урнаштыру - мәсьәләсен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнәавыл җирлеге Кече Әтнә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Кече Әтнә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма
комитет җитәкчесе: Хайрутдинов А.Г.